**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

«10» апрель 2024 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Тукай торак пунктында 23.11.2023 ел № 5 гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Тукай торак пунктында гражданнар җыены 23.11.2023 ел № 6 карары турында алдан расланган карарга түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2024 елда Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пунктында яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан, 1 гр инвалидлардан тыш, 2000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Тукай бистәсе территориясен төзекләндерү һәм тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х. Хәнәфиев

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Хәнәфиев